Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Майская Горка авыл җирлеге составына керүче Майская Горка торак пунктында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2020 елның 28 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Майская Горка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 15.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Майская Горка авыл җирлегенең Майская Горка торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Майская Горка авыл җирлеге Майская Горка торак пункты территория сендә яшәү урыны буенчат еркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белеем алучы студентлардан тыш, 2021 елда 4000 сум күләмендә үзара салым кертергә, ә 2 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар һәм күп балалы гаиләләр өчен түләүләр күләме гражданнар җыены карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.
2. Алынган акчаларны юнәлдерергә:

- буаны төзекләндерү (килешү буенча түләү);
- чишмәне төзекләндерү (килешү буенча түләү);
- балалар мәйданчыгын төзекләндерү (уен җиһазларын сатып алу һәм урнаштыру).

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Майская Горка авыл җирлеге башлыгы А.П. Морозов

ОГРН 1021602514416 МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ ... МАЙСКОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» ИНН 1630003154